# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Аю авыл җирлеге
Дружба торак пунктында 2024 елда гражданнардан
үзара салым кертү турында

**20.11.2023 ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлеге Дружба торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1.2024 елда Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлеге Дружба торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә,1,2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлдерү:

1) Дружба торак пунктында Тапиков урамында су белән тәэмин итү челтәрләрен төзү (траншеяләр эшләү, торбалар салу, килешү буенча эш өчен түләү);

2) Дружба торак пунктында су күтәрү торбасы, насос һәм насос станциясе төзелеше белән разведка-эксплуатация скважинасын бораулау (килешү буенча эш өчен түләү).

3. Әлеге карарны Аю авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (http://menzelinsk.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районынын
Аю авыл җирлеге башлыгы ____________________ А.М.Галимов
(имза)